# ПРОЕКТ

## «Экологик конституция!»

2002 нче елның 19 апрелендә Татарстан Дәүләт Советы тарафыннан республика Конституциясенең яңа редакциясе кабул ителде. Конституциядә кеше, аның хокуклары һәм иреге иң зур байлык дип игълан ителә. Һәм Татарстан Республикасының бурычы - кеше һәм гражданның хокукларын һәм иреген танырга, үтәргә һәм якларга. Татарстан Конституциясендә шулай ук гомуми сайлау хокукы, сүз һәм вөҗдан иреге, сәяси партия һәм оешмаларда катнашу мөмкинлеге кебек принциплар урын алган

# Татарстан Республикасы Конституциясе -

Татарстан Җөмһүриятенен төп кануны

- Әлеге Конституция, Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы һәм татар халкы ихтыярын чагылдырып,
- кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең өстенлеген гамәлгә ашыра,
- халыкларның гомумтанылган үзбилгеләнү хокукына, аларның тигез хокуклылыгы, ихтыяр белдерүнең иреклелегe һәм бәйсезлеге принципларына нигезләнә,

- тарихи, милли һәм рухи традицияләрнең, мәдәниятләрнең, телләрнең сакланып калуына һәм үсешенә, гражданнар татулыгын һәм милләтара килешүне тәэмин итүгә ярдәм итә,
- демократиянең ныгуына, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә, Русия Федерациясе халыкларының федерализм принципларында тарихи барлыкка килгән бердәмлеген саклап калуга шартлар булдыра.

# Хокуклар -

кешегә шәхес буларак яшәү һәм үсү өчен кирәк шартлар. Һәрбер кешенең яшәргә, ирекле һәм бәхетле булырга хокукы бар. Ә балаларның аерым хокуклары да бар. Бу белем алу, әти-әни белән яшәү, хөкүмәт тарафыннан яклану хокукы

# Бурычлар –

кеше тарафыннан ул үзе һәм калган-
нар тыныч кына яшәсеннәр һәм эш-
ләсеннәр өчен башкарылырга тиеш
хәрәкәтләр. Һәрбер кеше башлангыч
һәм төп мәктәпне тәмамларга тиеш,
урлашмаска, салымнарны вакытында
түләргә бурычлы.

| Хокуклар | Бурычлар |
|---|---|
| **Хезмәткә хокук** | Дәүләтебезнең Конституциясен һәм законнарын үтәү |
| **Ял итүгә хокук**<br>**Сәламәтлекне саклауга хокук**<br>**Белем алуга хокук** | Ватанны саклау<br>Балаларны кайгырту, тәрбияләү<br>Табигатьне саклау, табигый байлыкларга сакчыл мөнәсәбәт |
| **Шәхси тормышыңның, торак йортыңның кагылгысызлыгына хокук** | Салымнар түләү |
| **Ил буйлап ирекле күченүгә һәм яшәү урынын сайлауга хокук** | Тарихи һәм мәдәни ядкарьләр турында кайгырту |

# *Бала хокуклары турындагы конвенция*

1989 елның ноябре – Берләшкән Милләтләр Оешмасының Бала хокуклары турындагы Конвенциясен кабул иткән көн.

Россиядә Конвенция 1990 елның 15 сентябрендә гамәлгә керде.

Конвенция, 18 яшькә кадәрге һәрбер кешенең шәхси хокуклары күрсәтелгән, 54 маддәдән тора.

| Хокуклар - | Бурычлар- |
| --- | --- |
| Яшәү хокукы | Башлангыч һәм төп белем алу бурычы |
| Гражданлык хокукы | Салымнарны вакытында түләү |
| Ата-аналар белән яшәү | Тирә-юньдәгеләрнең иминлегенә зыян китермәү |
| Ял хокукы | Алдашмау |
| Белем алу хокукы | Тирә-юнь мохитны саклау |
| Сүз иреге | Урлашмаска |
| Яшәү урынына хокук | Өлкән яшьтәгеләргә һәм авыларга һәрчак ярдәм итү |
| Дәүләт органнарына сайлау һәм сайлану | |

# Проект «Безнең дуртаяклы дусларыбыз-ны саклагыз!»

# Җәнлекләр-нең хокуклары:

-табигатьтән яшәү өчен әһәмиятле шартлар: яктылык һәм җылылык, сулау өчен һава, сыену урыны һәм ризык алу;

- әйләнә-тирәнең шартлары төрле булган территорияләрен биләп алу;
- үзебезнең балаларыбызны саклау;
- төрле саклану чараларына ия булу;
- туклану чаралары буенча төрлечә булу;
- кыргый җәнлекләрне кешеләр тарафыннан аулауда һәм тотуда чикләү таләп итү;
- йорт хайваннары кешеләрдән асрау өчен тиешле шартлар таләп итү;
- юкка чыгып баручы сирәк очрый торган төрләрне тергезергә һәм сакларга.

# Җәнлекләр-нең бурычлары:

- планетаны матурларга, кешеләрләрдә мәрхәмәтлелек хисе һәм барлык тереклеккә карата хөрмәт хисе тәрбияләү;
- туклану чылбыры составына керү;
- үсемлекләргә ашлама чыганагы булып хезмәт итү, туклану өчен углекислый газ, орлыкларын тарату чарасы булу;
- кешегә хуҗалыкта, авыл хуҗалыгында, промышленностьта, йортларны саклауда, йөк ташыганда, ризык табуда, йон бирүдә ярдәм итәргә һәм башкалар.

# ПРОЕКТ

## «Безнең яшел дусларыбыз»

# Үсемлекләрнең хокуклары:

-табигатьтән яшәү өчен әһәмиятле шартлар алу: яктылык һәм җылылык, һава, су, минераль тозлар;

- әйләнә-тирәнең шартлары төрле булган территория-ләрен биләп алу;
- үзләренең орлыкларын төрле юллар белән тарату: һава, су, "атылу", хайваннар һәм кешеләр ярдәмендә;
- төрле үзлекләргә ия булу: чәнечкеле, агулы, чагучы һәм б.т.
- үзеңә хөрмәт, кайгырту, саклау таләп итү;
- юкка чыгып баручы сирәк очрый торган төрләрне тергезергә һәм сакларга.

# Үсемлекләрнең бурычлары:

-табигатьне бизәү, кешегә шатлык, куаныч бүләк итү;

-кислород бүлеп чыгару, һаваны углекислый газдан чистарту, тавыш һәм тузанны тоткарлау;

-җәнлекләрне сыену урыны һәм ризык белән тәэмин итү;

- кешеләргә һәм хайваннарга дару үләннәре җитештерү;
- кешегә туклану продукты сыйфатында, кием – салым, мебель һәм б. җитештерү материалы буларак хезмәт итү.

- **2 бирем. Акыл штурмы.** «Агачлар- безнең яшел дуслар»диләр. Ни өчен?

# Агач -

- -дус,
- дәвалаучы,
- тавышны йота,
- саклаучы,
- һаваны микробтан чистарта,
- кислород чыганагы булып тора,
- -елганы мул сулы итә,
- тауларны җимерелүдән саклый,
- туфракны таркалудан саклый,
- төзелеш материалы,
- туендыручы.